СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЗАЙ-КАРАТАЙСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЗӘЙ-КАРАТАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2023 елның 1 августыннан

№28

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 5 июнендәге 20 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Зәй-Каратай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 5 июнендәге 20 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта 10, 11, 12), 13) пунктчаларын төшереп калдырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зәй-Каратай авылы, Совет урамы, 99 йорт, 1 бина, Үзбәк авылы, Луговая урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.https://leninogorsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Зәй-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

М.И.Идиятова